**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МОНАСТЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422392, Республика Татарстан, Тетюшский район, с. Монастырское, ул. Комсомольская, д.33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОНАСТЫРСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422392, Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Монастырск авылы, Комсомол урамы, 33

Тел. (84373)5-45-20, факс: 5-45-20, e-mail: monastyr.tetushi@tatar.ru
ОКПО 93065239, ОГРН 1061672018187, ИНН/КПП:1638005114/16380100

**11.03.2025** **№27**

**Постановление** **Карар**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырь авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Монастырь авыл җирлеге бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- һәр салым чыгымы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Монастырь авыл җирлеге бюджетына түләүчеләр тарафыннан түләү өчен декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.А.Васин**